**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәсгут авыл җирлегенең Советы**
**КАРАРЫ**

Мәсгут авылы № 158-95 «16» апрель 2025 ел

Бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең Мәсгут Советына депутатлар сайлауларны уздыру өчен Татарстан Республикасы

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларыньщ һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актубэ шэйэр тибындагы поселогы» муниципаль берэмлеге Уставының 32 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 16 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълуматын рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (aznakayevo.tatarstan.ru), махсус мәгълумат стендларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан, түбәндәге адреслар буенча:
Мәсгут ав., Г.Багманова ур., 16 йорт (мәдәният йорты бинасы).
Якши-Бай ав., Лесная ур.( мәгълүмати стенд)

3. Карар ул басылып чыкканнан соң уз көченә керә.

Рәис А.Л.Гимадиев

Татарстан Республикакасы
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге Советы
карарына кушымта №1
“16” апрель 2025 №158-95

Бермандатлы сайлау округлары схемасы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең Мәсгут Советына депутатлар сайлау буенча

| № п/п | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәсгут № 1 | **Мәсгут авылы**<br>ул.Дружба от д.№ 1 по д.№ 35 | 43 |
| 2 | Мәсгут № 2 | **Мәсгут авылы**<br>ул.Дружба от д.№ 36 по д.№ 55,<br>ул.8 Марта от д.№ 1 по д.№ 6 | 44 |
| 3 | Мәсгут № 3 | **Мәсгут авылы**<br>ул.8 Марта от д.№ 7 по д.№ 27 | 41 |
| 4 | Мәсгут № 4 | **Мәсгут авылы**<br>ул.Багманова от д.№ 2 по д.№ 13,<br>у.8 Марта от д.№ 28 по д.№ 59 | 39 |
| 5 | Мәсгут № 5 | **Мәсгут авылы**<br>ул.1 Мая,<br>ул.Багманова от д.№ 18 по д.№ 28 | 43 |
| 6 | Мәсгут № 6 | **Мәсгут авылы**<br>ул.Багманова от д.№ 29 по д.№ 61 | 44 |
| 7 | Мәсгут № 7 | **Якши-Бай авылы** | 46 |